# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Бикбау авыл җирлеге составына кергән Бикбау торак пунктында
халык җыены нәтиҗәләре турында

**14.11.2020ел.** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 14 ноябрендә узган халык җыены нәтиҗәләре белән халык җыенының йомгаклау беркетмәсе түбәндәге мәсьәлә буенча төзелде: "2021 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең Бикбау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә (*1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, БВС һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннары,күпбалалы гаиләләр, көндезге бүлектә укучы студентлар, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнадан тыш*) үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә Сез ризамы?":

1) Бикбау торак пунктында Ленин, Садовая, Береговая урамнары тыкрыклары (4 тыкрык) буйлап сууткәргеч челтәрләр сузу (торбалар сатып алу, эшләр өчен килешү нигезендә түләү).

2) Бикбау торак пунктында суэтем башнясына су бирү скважинасын тоташтыру (торбалар сатып алу, эшләр өчен килешү нигезендә түләү).

3) Бикбау торак пунктында Ленин урамында балалар мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру (материал сатып алу, килешү нигезендә түләү);
4) Бикбау торак пунктында Ленин урамында җәяүлеләр сукмагы салу (10 м) (материал сатып алу, килешү нигезендә түләү);

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган катнашучылар исемлегенә 368 халык җыенында катнашучы кертелгән, халык җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны - 185 кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
җыенда катнашкан 175 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 10 кеше тавыш бирде.
Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар бирде:

1.Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең Бикбау торак пунктында халык җыены узуын танырга, халык җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

"2021 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең Бикбау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә (*1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, БВС һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннары,күпбалалы гаиләләр, көндезге бүлектә укучы студентлар, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнадан тыш*) үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә Сез ризамы?" мәсьәләсе буенча карарны танырга һәм түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:

1) Бикбау торак пунктында Ленин, Садовая, Береговая урамнары тыкрыклары (4 тыкрык) буйлап суүткәргеч челтәрләр сузу (торбалар сатып алу, эшләр өчен килешү нигезендә түләү).

2) Бикбау торак пунктында суэтем башнясына су бирү скважинасын тоташтыру (торбалар сатып алу, эшләр өчен килешү нигезендә түләү).

3) Бикбау торак пунктында Ленин урамында балалар мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру (материал сатып алу, килешү нигезендә түләү);
4) Бикбау торак пунктында Ленин урамында җәяүлеләр сукмагы салу (10 м) (материал сатып алу, килешү нигезендә түләү);

3. Бикбау авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен кабул ителгән көннән 7 көн эчендә Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында (https://menzelinsk.tatarstan.ru) хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Бикбау авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче ______________Л.Н.Мәрдәмшина

**Бикбау авыл җирлеге**
**башлыгы:** **Л.Н. Мәрдәмшина**